
Атюрьево районы ООО МАПО «Каменка» оешмасына нигез салынганнан бирле эшләvчеләрнен берсе - Наиль Фаиль улы Агеев.
Наиль Фаиль улы - ботен гомерен авыл хужалыгына багышлаган нәселдән - механизаторлар нәселеннән. Әтисе Фаильнен хезмәт стажы 42 елны тәшкил итә. Уллары Наиль белән Рафаэль дә әтисе юлыннан киткәннәр- икесе дә авыл хужалыгы техникасында эшлиләр.
Хәзерге вакытта Наиль Фаиль улы Агеев Джон-Дир тракторында эшли, парларны эшкәртә, козге чәчv эшләренә туфрак әзерли. Анын сvзләренә караганда, апрель аеннан сезонлы кыр эшләре башланды: жирне ашлама белән тукландыру, аннан чәчv, малларга азык әзерләгәндә печән ташу кебек эшләрне башкарган, ә хәзер инде парларны эшкәртv белән шогыльләнә һәм шулай карангы козгә кадәр.      Авыл хужалыгында яз-жәйләрне ял итәргә вакыт юк та юк, эшләргә теләгән механизаторга кыш коне дә эш табылып тора. Мәсәлән, яна сезон очен техника әзерләv буенча ремонт эшләрен башкару, моннан тыш, фермада да эш житәрлек. Кыскасы, эшкә кул һәм теләк булса, эш фронты һәрвакыт табылып тора авыл жирендә. Әйтеп китәргә кирәк; тырыш хезмәткәрләрне МАПО хужалыгы житәкчеләре хезмәт хакы белән кыерсытмый; авыл vлчәмнәре буенча яхшы тормышка житәрлек тvли. Менә шулай кvп еллар буе иртә таннан карангы тонгә кадәр туган як файдасына хезмәт куя Наиль Фаиль улы Агеев. Бvген дә, кыска гына сорауларга жавап биреп һәм тиз арада техниканын жимерелгән жирен тозәтеп, тракторын кабызды да басуга китте; жәйге эш котәргә яратмый шул. Хужалык житәкчесе В.Н.Кучеров vз эшчесен бик жаваплы һәм тырыш, ә ин моһиме, яхшы һәм намуслы кеше буларак характерлый. Ул аракы эчми, тәмәке тартмый, бар яктан да унган кеше, ди.
Язма героебыз аны шундый иттереп тәрбияләгән очен әти-әнисенә рәхмәтле. Әти-әнисе хәзер инде олылар: әтисенә - 81 яшь, ә әнисенә - 77 яшь. Әнисе дә, әтисе кебек vк, жирдән ерак китмәгән, гомере буе колхозда эшләгән. Агеевлар гаиләсендә оч бала тәрбияләнеп vскән: ике малай һәм бер кыз. Хәзер инде әби-бабайны шатландырып, дvрт оныклары һәм ике оныкчыклары vсә. Рафаэльләре Мәскәvдә яши, экскаваторда эшли, Риммалары да гаиләсе белән Мәскәvдә яшиләр. Наильләре генә әти-әнисе йортыннан китмәгән; аларны картлык коннәрендә ялгыз калдыра алмаган, туган жире дә жибәрмәгән. Әйе, ул абыйсы кебек vк Мәскәvгә китеп vз тормышын биредәгегә караганда кvпкә яхшырак алып бара алыр иде. Әмма туган жирендә яшәргә, карт әти-әниләренен тынычлыгын сакларга калганлыгын Наиль vзе дорес эшләгән дип саный.

Карт кешеләрне vзе белән шәһәргә алып барырга да булдырыр иде диярсез, тик риза булырлармы сон? Алар - борынгыдан чыныккан, кендек каны тамган жир кешеләре бит. Балалары ата-аналарын зур шәһәрләргә алып киткән очраклар бихисап, ә алар анда яши алмыйча йә кире кайткан, йә иртә vлгән очраклар кvпме! Тамырын корыткан агач кебек булыр кvк жирләре дә vләр дип тоела аларга.
Туган ягында калганына бер дә vкенми Наиль Фаиль улы Агеев; тамырлары кочле анын, шул тамырларын нәкъ туган жирендә саклап яши.

**Наилә Насырова**